

Ленинград блокадасы Ватан тарихынын героик битлəренен берсе һəм бер vк вакытта ин фажигалесе. 27 январьда, Ленинград шəһəрен Боек Ватан сугышы елларында фашистлар блокадасыннан азат итvнен 82 еллыгы vтте. Ул 1941 елнын 8 сентябреннəн 1944 елнын 27 январына кадəр дəвам итə. Тугыз йоз кон кайгы, газаплар, ачлык, батырлык, кеше ныклыгы... Бу датага Темников районы Митрялы авыл китапханəсе укучыларга «Сугыш. Блокада.      Ленинград» дип исемлəнгəн тарихи кvргəзмə тəкъдим итə. Китапханə житəкчесе Венера Рашит кызы Ялышева кvргəзмəдə фашист гаскəрлəре тарафыннан блокадалы Ленинградньн тинсез батырлыгы турында, шул ук вакытта Темников районы авылларынын берничə блокаднигы турында материалларны кvргəзмəгə урнаштыра. Алар- чолганышта калган Ленинградта яшəvчелəрнен авыр сынаулары: ачлык һəм зəхəри суык, заводларда ирлəр белəн беррəттəн эшлəгəн балалар һəм хатын-кызлар, Ленинградны саклау һəм обороналау турында шаһитлар. Шуларнын берсе – Сафия Рəхим кызы Акбулатова.
Татар Адае авылында яшəvче 99-яшьлек (7 январьда тулды) Темников районынын Мактаулы гражданы Сафия Рəхим кызы Акбулатова блокададагы Ленинградны яхшы хəтерли: онытып буламы сон!
1930 нчы елларда героинябызнын əти-əнисе, Сафия, Роза, Рая, Рашид балалары белəн, Темниковонын Аксел авылыннан Ленинградка акча эшлəргə киткəннəр. Бу шəһəрдə анын бабасы яшəгəн.
1941нче елны Боек Ватан сугышы башлана. Ленинград шəһəре блокадасы коточкыч кышы килеп житə. Ачлыктан vлvчелəр арасында балалар да кvп була. Икмəкне карточкалар буенча алганнар. Кыскасы – сугыш, ачлык, зəмхəри салкын...Тарих битлəреннəн тvгел, ə vзе Сафия Рəхим кызы татыган хəллəр. Мəсəлəн, салкыннан бик кvп одеяллар астында жылынырга тырышып, бишəv бер кроватьта йоклаганнар. Берконне иртəн Сафия 8 яшьлек апасы Раянын vле гəvдəсен кочаклап йоклавын ачыклаган. Берникадəр вакыттан сон əнисе vлə. Əниесе vлгəч, ятим калган балаларны кvрше йортта яшəvче əнисенен дусты Нюра апа vз янына ала. Ул сонгы ипи бортеклəрен алар белəн бvлешкəн. Берничə айдан 7 яшьлек эне Рашид та vлə. 1942 елнын кышында Сафия белəн Розаны, башка Ленинград балалары белəн бергə, Ладога кvле буйлап «зур жиргə» озаталар. Кайдадыр якында гына снарядлар шартлый, блалар бер-берсен кочак

лый. Могжиза белән исән калып, Мордовиягә апалы - сенелле туган авылы Темников районы Татар Адае авылындагы бабайлары йортына житеп яши башлыйлар. Ул вакытта Сафиягә 15 яшь була. Алты классны Ленинградта тәмамларга олгергән кызга авылда укырга урын булмый һәм Сафия Рәхим кызы колхозда эшли башлый. Сугыштан сон кичке мәктәпне тәмамлап, авыл клубына модир булып 62 яшендә кадәр эшли. Роза апасы Ленинградка кайта.
- Мин Боек Ватан сугышында исән калганнарнын барысын да геройлар дип саныйм, - ди Сафия Рәхим кызы. - Без vлемне жинеп, ин моһиме- кешелеклелекне саклап кала алдык!
Тагы бер блокадачы - Мешвика Камалетдин кызы Урусова.
1934нче елда Ленинград шәһәрендә туган кыз бала Боек Ватан сугышы башлануны туган шәһәрендә каршы ала. Мешвика Камалетдин кызы эвакуировать ителергә олгермичә гаиләләре белән чолганышта кала. Шул вакыт ул, олылар белән бергә, авианалетлар вакытында ой тvбәләрендә кизv тора, бомбалар сvндерешә, ком, су ташый.
Балачактан анын хәтерендә сугыш, ачлык, әнисе кvзләре генә кала. Нива елгасыннан әнисе, апалары белән су ташулары тошенә кереп калтыранып озак еллар уяна торган була.

Апалары - сенелләре ачлыктан vләләр. Ике ел газаплардан сон Темников районындагы әтисе туган Идеево авылына юл тоталар, әмма әнисе юлда vлә. Мешвика Камалетдин кызы әнисенен мәетен поезддан ташлаганнарын vз кvзләре белән кvрә, әмма нинди тукталыкта икәнен хәтерләми. Үзләре белән бер вагонда барган юлчылар Мешвиканы Митрялы авылындагы әбисенә юллыйлар һәм әбисе аны тәрбияли. Бу бик кыркыныч сугыш еллары иде дип искә ала булган Мешвика Камалетдин кызы Урусова.
Ленинград блокадасынын ачысын татыгын Абидулла Ибраһим улы Ялышев 1930 елнын 10 январында Ленинграднын Василеостров районында туа. Ун яшьлек малай буларак Боек Ватан сугышын каршы ала ул. Шәһәрдә берни ашарга калмый. Ачлыктан vлмәс очен утын ярган, оч километр ераклыктагы Нива елгасына суга йоргән. Шунын очен аны кvршеләре кычыткан шулпасы ашатканнар. Яз башлары житкәч, Ленинград яны кырларыннан тунган бәрәнге жыеп ашаганнар. Шулай ачтан vлми калган ул.
Озак еллар колагында бомбалар шартлавы ишетелеп торган Абидулла Ибраһим улынын. Олысы-кечесе бергә яна торган бомбалаврны сvндерегәннәр, жимерек ойләр оемнәрен сvткәннәр. Бик куркыныч вакытлар кичергән ул: тирә-якта vле гәvдәләр...Халык барган жиреннән vлеп киткәннәр. Блокада вакытында Абидулла Ибраһим улынын ике браты vлгән.
1943нче елнын козендә аларнын ойләренә бомба тошә. Яшәргә урыннары калмагач, биш кешеле гаилә эвакуировать ителәләр. Ладога кvле аркылы чыкканда, бомбага тотмаганнар аларны һәм Казанга исән-сау житкәннәр алар. Юлда ашарга дип бирелгән паектан сон, Казандагы бодай боткасы белән ипи vзенчә бәхет булып тоелганы истә анын.
Казаннан Темников районы Митрялы авылына кадәр егерме кондә килеп житкәннәр. Башта хужалыкларга билгеләсәләр vзләрен, бераздан әтиләре кечкенә генә йорт сатып ала. Әтиләре Ибриһимны Митрялы авылыннан фронтка алалар. Озакламый сукыраеп ойләренә әйләнеп кайта.

- Ул чакта кvргәннәрне, ул вакыттагы кичерешләрне мәнге онытасым юк. Блокадалы 125 граммлы ипине гомерем буе оныта алмыйм: коточкыч!
Илләр һәрвакыт тыныч булсын! -кvз яшьләрен тоя алмый сойләп калдырган Абидулла Ибраһим улы Ялышев. Абидулла Ибраһим улы Ялышев 2016нчы елнын 2 мартында бакыйлыкка кvчә.
Тагы бер Темников районы Митрялы авылы блокадницасы турында. Магинюр Абубәкәр кызы Кичемасова 1936нчы елнын 12 октябендә Кронштадт шәһәрендә туа. Әнисе 6-8 яшьлек уллы иргә кияvгә чыга һәм тагы 2 кыз, малай белән Магинюр доньяга киләләр. Аларнын йортлары ипи ларёгы янында була һәм соры ипи тоере очен озын-озак чиратлар торулары исенә уелып калган. Аларнын гаиләләреннән абыйсы ипи очен йоргән һәм ойләренә кайтканда шул ипи тоере валчыгын каба-каба ипи юк дигән хәлгә житә торган булган. Ачлыкнын тәме дә ачы. Ә Магинюр браты белән балалар бакчасына йоргән. Анда аларны шулпага охшаган сыек нәрсә белән ашата торган булганнар. Магинюрнын браты, ачлыктан шешенгән әнисенә, vзенә бирелгән шулпа нормасыннан берәзен банкага салып алып кайта торган булган. Шулай иттереп әнисе дә ачлыктан vлми кала. Магинюр Абубәкәр кызы ачы Боек Ватан сугышынын беркайчан онытылмый торган шатлыклы мизгел булып калган хәл дә булганын сойләп калдырган: бервакыт шул ипи ларёгы бомбага эләгә һәм бомба дулкыны белән Магинюрлар коридорына тугыз буханка ипи килеп тошә. Шул вакыттагы шатлык хисе бvген дә истә анын, әмма барысы да кемнәрнен дә гомер хакы икәнен ачык анласалар да.
Магинюр балачактан инвалид. Бомбежка вакытында егылып тезен имгәтә.Чыккан урынын тезәтәселәре булган: сугыш вакытында нинди тез утырту! Шулай гомерлеккә кала.
Ничек Мордовиягә эләгәләр дигән сорау туа. Әтисе окоплар казыганда бомбежкага эләгеп vлгәч (кvмәрлек жире калмаган була), әлеге гаиләнен хәле тагы да яманлана: каты ачлыктан абыйлары vлеп бетә. Магинюр әнисе белән икәv генә исән кала. Кvп кенә иза чиккәннән сон, Мордовия якларына эвакуацияләнәләр. Коч-хәл белән Барашевога кадәр житәләр. Әнисе кер юучы булып эшкә урнаша. Бераздан ниндидер транспорт табып Адаевога, туганнарына кадәр киләләр. Бераз хәл жыйгач кына Митрялы авылында яшәгән әбисенә кадәр житәләр.
1918нче елнын 17 февралендә Магинюр Абубәкәр кызы vлә. Ул Блокадалы Ленинград медале белән бvләкләнгән.
Адиля Умәр кызы Кичемасова Ленинград блокадницасы һәм башкалары, һәм башкалары безнен хәтердә.
Ленинград блокадасы темасы, Ленинград блокадасы vзе - халыкнын ин боек батырлыгы да, ин боек фажигасе дә ул! 1941 елнын сентябрендә башланган фажига 1944 елда гына тәмамланган - блоканы тулысынча бетергәннән сон! Алар газапларга тvзеп, бернәрсәгә карамастан, кешелек дәрәжәсен саклап калганнар һәм туган шәһәрләрен яклаганнар. Каһарманнарга тvбәнчелек белән баш иеп мәнгелек хәтер!

**Наилә НАСЫРОВА**